| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 гыйнвар 2025 ел. № 119

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Карадуган авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Карадуган авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставын Федераль законга туры китерү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

-1 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә: “Муниципаль берәмлекнең кыскартылган исеме-ТР БМР Карадуган авыл җирлеге";

- 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

21) "шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

-19 статьяның 5 пунктындагы 2 абзацында "1-7 пунктларында" сүзләрен "1-7 һәм 9.2 пунктларында"сүзләренә алмаштырырга.;

-42 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле: «12) чит ил агенты статусын алу»12 пунктчасы өстәргә;

-51 статьяның 1 пунктындагы 1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:

«шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.».

-Уставның 75 статьясына түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Җирлекнең, Россия Федерациясенең җирле үзидарә органнары электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасының яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасының электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыралар.»

2.Әлеге карарны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3.Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baitasi.tatarstan.ru) «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә алам.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы,
Карадуган авыл җирлеге Советы рәисе Ш.В.Низамиев